КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 март г.Казань № 240

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 8 июнь, 439 нчы карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 8 июнь, 439 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 11 август, 704 нче; 2021 ел, 15 ноябрь, 1077 нче; 2021 ел, 29 декабрь, 1312 нче; 2022 ел, 3 октябрь, 1061 нче, 2022 ел, 10 ноябрь, 1193 нче, 2022 ел, 24 декабрь, 1413 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә

ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авиаташучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик заты капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

11 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авиаташучының офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, авиаташучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы тарафыннан кул куелган һәм мөһер (булганда) сугылган белешмә кәгазен;»;

17 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе) һәм аның тасвирнамәләре (субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр) (алга таба – тасвирнамәләр);»;

Тәртипнең кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 14 март, 240 нчы карары редакциясендә)

2023 елга Татарстан Республикасы территориясеннән һәм (яки) территориясенә гамәлгә ашырыла торган һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең субсидия бирелә торган маршрутлары исемлеге

| Т/с | Һава транспорты белән пассажирлар йөртү маршрутлары | | Атнага рейслар ешлыгы | Елга рейслар ешлыгы | Махсус тарифның чик зурлыгы, сум | Бер парлы рейска Татарстан Республикасы бюджетыннан авиапассажирлар йөртүчеләргә бирелә торган субсидия күләме, сум | Һавада йөртүләрне башкару чоры |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | очып китү аэропорты | барып җитү аэропорты | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Казан | Архангельск | 2 | 47 | 6 606,0 | 148 401,0 | 01.01.2023 – 30.04.2023, 01.11.2023 – 31.12.2023 |
| 2. | Казан | Әстерхан | 2 | 43 | 6 123,0 | 139 726,6 | 01.01.2023 – 31.05.2023 |
| 3. | Казан | Барнаул | 2 | 44 | 10 953,0 | 223 336,25 | 02.01.2023 – 30.06.2023, 01.09.2023 – 31.12.2023 |
| 4. | Казан | Волгоград | 2 | 43 | 5 157,0 | 117 431,1 | 01.01.2023 – 31.05.2023 |
| 5. | Казан | Кемерово | 2 | 49 | 10 953,0 | 223 336,25 | 02.01.2023 – 31.05.2023, 01.10.2023 – 31.12.2023 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Казан | Магнитогорск | 2 | 52 | 7 191,0 | 95 134,99 | 02.01.2023 – 31.05.2023, 01.09.2023 – 31.12.2023 |
| 7. | Казан | Мурманск | 2 | 49 | 9 021,0 | 223 336,25 | 02.01.2023 – 31.05.2023, 01.10.2023 – 31.12.2023 |
| 8. | Казан | Түбән Новгород | 2 | 50 | 2 741,0 | 61 691,13 | 02.01.2023 – 31.05.2023, 01.10.2023 – 31.12.2023 |
| 9. | Казан | Новокузнецк | 2 | 32 | 10 953,0 | 246361,31 | 01.01.2023 – 30.04.2023 |
| 10. | Казан | Омск | 2 | 52 | 8 538,0 | 246 361,31 | 01.01.2023 – 31.05.2023, 01.09.2023 – 31.12.2023 |
| 11. | Казан | Оренбург | 3 | 52 | 3 708,0 | 83 987,24 | 02.01.2023 – 31.05.2023, 01.09.2023 – 31.12.2023 |
| 12. | Казан | Пермь | 2 | 48 | 3 225,0 | 72 839,49 | 02.01.2023 – 31.05.2023, 01.10.2023 – 31.12.2023 |
| 13. | Казан | Самара | 2 | 49 | 2 258,0 | 50 543,38 | 02.01.2023 – 31.05.2023, 01.10.2023 – 31.12.2023 |
| 14. | Казан | Саратов | 2 | 84 | 3 225,0 | 72 839,49 | 02.01.2023 – 31.12.2023 |
| 15. | Казан | Сургут | 2 | 57 | 8 538,0 | 366 125,0 | 02.01.2023 – 31.05.2023, 01.09.2023 – 31.12.2023 |
| 16. | Казан | Ханты-Мансийск | 2 | 84 | 7 089,0 | 137 374,0 | 01.01.2023 – 31.12.2023 |
| 17. | Казан | Чиләбе | 2 | 54 | 4 767,0 | 126 431,65 | 01.01.2023 – 31.05.2023, 01.10.2023 – |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | 31.12.2023 |
| 18. | Казан | Ярославль | 2 | 40 | 3 708,0 | 83 987,24 | 02.01.2023 – 31.05.2023, 01.10.2023 – 31.12.2023 |
| 19. | Казан | Нарьян-Мар | 2 | 126 | 7 572,0 | 137 374,0 | 01.01.2023 – 31.12.2023 |
| 20. | Казан | Сыктывкар | 2 | 84 | 4 191,0 | 77 979,5 | 01.01.2023 – 31.12.2023 |
| 21. | Түбән Кама | Минерал Сулар | 2 | 26 | 8 055,0 | 246 361,31 | 01.01.2023 – 31.03.2023 |
| 22. | Түбән Кама | Нижневартовск | 2 | 23 | 8 538,0 | 403 871,0 | 01.01.2023 – 31.05.2023 |
| 23. | Түбән Кама | Яңа Уренгой | 2 | 52 | 9 504,0 | 403 871,0 | 01.01.2023 – 31.05.2023, 01.09.2023 – 31.12.2023 |
| 24. | Түбән Кама | Сургут | 2 | 52 | 7 572,0 | 310 249,0 | 01.01.2023 – 31.05.2023, 01.09.2023 – 31.12.2023 |
| 25. | Түбән Кама | Новосибирск | 2 | 52 | 10 470,0 | 237 257,67 | 01.01.2023 – 31.12.2023 |